**Халык жыены карары**

№ 1 25.11.2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

Югары Стәрле авыл җирлеге составына керүче Югары

Стәрле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең Югары Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләр ,укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә киметергә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү очен алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Югары Стәрледә юлларны тигезләү ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрле авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Җиңү көне», “Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне»» бәйрәм чаралары үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Югары Стәрле авылында халык күплəп ял итә торган урыннарны төзекләндерү «Мин яратам Стәрле» стеласын (сатып алу һәм урнаштыру);
- Югары Стәрле авылы урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Югары Стәрле авылында да күмелгән урыннарны карап тоту (тоташ гербицид белән химик эшкәртү, чүп-чар җыю, агач кисү);
- Югары Стәрле авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне чүп үләннәреннән, корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, агачлар һәм куаклар, чәчәкләр утырту , килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре күрсәтү);
- Югары Стәрле авылы зират бинасын тышлау өчен төзелеш материаллары сатып алу.

РИЗА» «КАРШЫ».

Халык жыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 363 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 187 кеше кергән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 187 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
Азнакай муниципаль районы составына керүче Югары Стәрле авыл җирлегендә узган халык җыенын халык җыенын утте дип танырга,
халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.
"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Югары Стәрледә юлларны тигезләү ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрле авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Җиңү көне», “Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне»» бәйрәм чаралары үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Югары Стәрле авылында халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү «Мин яратам Стәрле» стеласын (сатып алу һәм урнаштыру);
-Югары Стәрле авылы урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Югары Стәрле авылында да күмелгән урыннарны карап тоту (тоташ гербицид белән химик эшкәртү, чүп-чар җыю, агач кисү);
- Югары Стәрле авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне чүп үләннәреннән, корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, агачлар һәм куаклар, чәчәкләр утырту , килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре күрсәтү);
- Югары Стәрле авылы зират бинасын тышлау өчен төзелеш материаллары сатып алу.

3.Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 32г, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет ур., 57 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Беренчемай ур., 30 , Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Тынычлык ур 16,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

Югары Стәрле авылы, Октябрь ур., 39А Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Октябрь ур., 9 адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.